ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

24.12.2024
2180

**КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары базасында бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл җыйган чыгарылыш укучыларына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгының еллык грантын бирү турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1600 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 272-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары базасында бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл җыйган чыгарылыш укучыларны бүләкләү максатыннан, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1 Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары базасында бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл җыйган чыгарылыш укучыларына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгының еллык грантын бирү турында» 2023 елның 17 октябрендәге 1600 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «11. Грант чараларын түбәндәгеләргә юнәлдерелергә мөмкин:

- матди-техник базаны яңартуга;
- ремонт эшләрен башкаруга;

- бердәм дәүләт имтиханында максималь күләмдә балл (100) җыйган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләгән укытучыларны бүләкләүгә;
- бердәм дәүләт имтиханында максималь санда баллар (100) җыйган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләү эшләрен оештырган өчен гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләрен бүләкләүгә.».

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева